ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН БИШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

16.08.2018 ел № 132

**2018-2027 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 26, 57.1 статьялары, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 декабрендәге 456-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын тотрыклы һәм нәтиҗәле үстерүне тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018-2027 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын (алга таба – программа) расларга.
2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы кул куелганнан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Д.В.Насертдинов**